**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай**
**муниципаль районы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592)
7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс
(885592) 7-23-85
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__11____» ___09______ 2026 ел. № ____215____

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 18 ноябрендәге 327 номерлы Азнакай муниципаль районы башлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында коррупциягә каршы эшне координацияләү комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында» 2010 елның 01 июлендәге 821 номерлы Указы нигезендә, 2026 елның 10 июнендәге 02-08-02-2026/Прп263-26-20920040 номерлы Азнакай шәһәре прокуратурасының протестын исәпкә алып, карар бирәм:

1.«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 18 ноябрендәге 327 номерлы Азнакай муниципаль районы башлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында коррупциягә каршы эшне координацияләү комиссия составына (20.05.2016 №153, 05.08.2016 №233, 10.11.2016 №351, 04.10.19 №314, 02.04.2021 №113, 31.08.2021 №255, 23.10.2025 №222 карарлар редакциясендә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. IV бүлекнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Комиссия составына федераль дәүләт органнарының һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Азнакай муниципаль районы территориясендә урнашкан территориаль бүлекчәләре, җирле үзидарә органнары җитәкчеләре, Азнакай муниципаль районы Иҗтимагый советы вәкилләре, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре керергә мөмкин.

.1.3. 4 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 8.1 пункт белән тулыландырырга.

«8.1. Комиссия составы комиссия кабул итә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеген булдырмау өчен төзелә.»;

1.4. 5 бүлекне түбәндәге эчтәлекле 16.1., 16.2 пунктлар белән тулыландырырга: .

«16.1. Комиссия утырышында комиссия әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы дип санала. Җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче комиссия әгъзалары катнашында гына утырышлар үткәрү мөмкин түгел.

16.2. Комиссия әгъзасының яисә рәисенең турыдан-туры яисә читләтелгән шәхси кызыксынуы барлыкка килгәндә, ул комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләне караганда мәнфәгатьләр конфликтына китерергә мөмкин, бу хакта утырыш башланганчы әйтергә тиеш. Мондый очракта комиссиянең әгъзасы күрсәтелгән мәсьәләне карауда катнашмый.».

2. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе турында» 2015 елның 18 ноябрендәге 327 номерлы Азнакай муниципаль районы башлыгы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында коррупциягә каршы эшне координацияләү комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Комиссия составыннан К. Ф. Баһаутдиновны, М.В. Сибагатовны, Ф. А. Сәлимовны чыгарырга;

2.2.комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

- Хәйруллин Рөстәм Рәшит улын, Россия Федерациясе тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең Азнакай районара тикшерү бүлеге җитәкчесен, аны комиссия әгъзасы итеп килешү буенча;

- Шәрәфиев Радик Рафаил улын, Россия Эчке эшләр министрлыгының Азнакай районы буенча бүлек җитәкчесен, аны комиссия әгъзасы итеп раслап, килешү буенча;

- Гыймалтдинов Марат Вил улын, ТР Азнакай шәһәр прокуроры, аны комиссия әгъзасы итеп раслап, килешү буенча.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык вазифаларын башкаручы А. Ф. Хәлиуллин

Азнакай муниципаль районы башлыгы карарына №1 кушымта
«___11_»____09___ 2026 № _215____

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында коррупциягә каршы көрәш буенча эшне координацияләү комиссиясе составы

*Комиссия рәисе:*

| | |
|---|---|
| Шәйдуллин Марсель Зөфәр Улы | Азнакай муниципаль районы башлыгы |

*Комиссия рәисе урынбасары:*

| | |
|---|---|
| Хәлиуллин Айдар Фәндәс улы | Азнакай муниципаль районы башлыгы урынбасары |

Комиссиянең җаваплы секретаре:

| | |
|---|---|
| Гатиятуллин Рамил Гамбәр улы | Азнакай муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе |

*Комиссия әгъзалары:*

| | |
|---|---|
| Әхмәдишина Лилия Мөгамбәр кызы | "Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе" МКУ җитәкче урынбасары-Азнакай муниципаль районының Иҗтимагый Советы рәисе (килешү буенча) |
| Хәйруллин Рөстәм Рәшит улы | Россия Федерациясе тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең Азнакай районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Габитова Зәйтүнә Сирин кызы | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Рәшитова Миләүшә Миргазиан кызы | Азнакай муниципаль районы ветераннарының (пенсионерларының) җирле иҗтимагый оешмасы Советы рәисе (килешү буенча) |
| Миңнеханов Азат Әзвәт улы | Федераль куркынычсызлык хезмәтенең ТР буенча идарәсенең Азнакай бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Салимова Наталья Викторовна | "Азнакай муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең “Контроль-хисап Палатасы" муниципаль казна учреждениесе рәисе |
| Шәрәфиев Радик Рафаил улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Азнакай районы буенча бүлек җитәкчесе, (килешү буенча) |
| Гыймалтдинов Марат Вил улы | ТР Азнакай шәһәр прокуроры, (килешү буенча) |
| Галиева Эльвира Сәйлүн кызы | ТР Азнакай районы Советы аппараты җитәкчесе |
| Магомедов Руслан Омаргаджи улы | Азнакай районы үзәк район хастаханәсенең сырхауханә эшләре буенча баш табиб урынбасары |

| | |
|---|---|
| Шәйхулов Фәрхәт Фәһим улы | «ТАТМЕДИА» АҖ «Маяк " газетасы редакциясе филиалы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Җиһангиров Әнвәр Әнсар улы | Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең эшкуарлыкны һәм фермерлыкны үстерү буенча ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Шакиров Илдар Хәлил улы | Азнакай муниципаль районының "Административ хуҗалык идарәсе" МБУ директоры урынбасары (килешү буенча) |